ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

30.09.2022 ел Баулы шәһәре № 199

Баулы муниципаль районы башкарма комитетының 2021 елның 28 маендагы 89 номерлы карары белән расланган «2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында энергияне сакчыл тоту һәм энергия нәтиҗәлелеген арттыру» муниципаль программасына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Энергияне сакчыл тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендә региональ һәм муниципаль программаларга таләпләрне раслау турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының үз көчләрен югалтуын һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләре үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2021 елның 11 февралендәге 161 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы башкарма комитетының 2021 елның 28 маендагы 89 номерлы карары белән расланган «2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында энергияне сакчыл тоту һәм энергия нәтиҗәлелеген арттыру» муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләрне кертергә:

I «Муниципаль программа паспорты» бүлегендә «Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» юлында 2 нче багананың эчтәлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Программаны финанслауның гомуми күләме 66806,52 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән еллар буенча: 2022 ел - 24956,60 мең сум; 2023 ел - 13870,35 мең сум; 2024 ел - 13023,15 мең сум; 2025 ел - 14956,42 мең сум. Искәрмә: Программаны финанслау күләмнәре фаразлау характерында була һәм тиешле дәрәҗәләрдәге бюджетларны тиешле елга һәм план чорына формалаштыруны исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш»;

1 нче «2022-2025 елларга төп программа чаралары» кушымтасын өстәргә (кушымта итеп бирелә);

2 нче «2022-2025 елларга энергия ресурслары һәм су күләмнәрен куллану буенча Баулы муниципаль районының максатчан күрсәткечләре» кушымтасын өстәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе
вазифаларын башкаручы И.И. Хөснуллина

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының
2022 елның 30 сентябрендәге
199 номерлы карары белән
расланган

«2021-2025 елларга Татарстан Республикасы
Баулы муниципаль районында
энергияне сакчыл тоту һәм энергия
нәтиҗәлелеген арттыру»
муниципаль программасына
1 нче кушымта

2022-2025 елларга төп программа чаралары

| № п/п | Чара атамасы | Чараларны тормышка ашыру сроклары | Финанс чыгымнарыы (мең сум) | Финанслау чыгымнары | Ягулык-энергетика ресурсларын экономияләү | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | Натураль чагылышта (кВтч, Гкал, куб.м.) | Бәя чагылышында (мең сум) |
| Баулы муниципаль районының торак фонды | | | | | | |
| 1. | фасадларны беркетү, пластик тәрәзә урнаштыру, күпфатирлы йортларда ишекләрне җылыту | 2022 ел<br>2023 ел<br>2024 ел<br>2025 ел | 14 205,96<br>8 630,00<br>9 200,00<br>11 600,00 | ТР бюджеты, җирле бюджет, бюджеттан тыш акчалар | 138,0 Гкал<br>154,0 Гкал<br>154,0 Гкал<br>154,0 Гкал | 291,49<br>325,28<br>325,28<br>325,28 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 2. | Күпфатирлы йортларда электр белән тәэмин итү челтәрләрен алыштыру, диодлы яктырткычлар урнаштыру | 2022 ел<br>2023 ел<br>2024 ел<br>2025 ел | 6 675,80<br>1 140,00<br>1 225,00<br>760,26 | ТР бюджеты, җирле бюджет, бюджеттан тыш акчалар | 5560,0 кВтч<br>6200,0 кВтч<br>6200,0 кВтч<br>6200,0 кВтч | 21,85<br>24,37<br>24,37<br>24,37 |
| «Газпром теплоэнерго Казань» ҖЧҖ «Баулы» филиалы | | | | | | |
| 3. | Гамәлдәге норматив документлар таләпләре нигезендә газны исәпкә алу узелларының модернизацияләү (казанлылар №10, 15, 17, 26, 27, 28, 29, ҮРБ) | 2022 ел | 1228,69 | бюджеттан тыш акчалар | - | - |
| 4. | Гамәлдәге норматив документлар таләпләре нигезендә газны исәпкә алу узелларын модернизацияләү (казанлылар №10, 15, 17, 26, 27, 28, 29, ҮРБ) | 2023 ел | 1472,20 | бюджеттан тыш акчалар | - | - |
| «Бәләкәч» 5 нче балалар бакчасы» МББМУ | | | | | | |
| 5. | Яктырткычларны алыштыру | 2023 ел | 15,0 | җирле бюджет | 70,0 кВтч | - |
| «6 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ | | | | | | |
| 6. | Яктырткычларны алыштыру | 2023 ел | 15,0 | җирле бюджет | 16,0 кВтч | - |
| Баулы муниципаль районының «Водоканал» МКП | | | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 7. | Замена насосных агрегатов (на импортные аналоги) | 2022-2025 еллар | 10 384,61 | ТР бюджеты | 797,0 Гкал | 524,7 |
| «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының мәдәният бүлеге» МКУ | | | | | | |
| 8. | Кызылъяр авылында шагыйрь Фәнис Яруллин музеенда җылылык системасын алыштыру Яктылык диодлы яктырткычлар һәм лампалар, TLD лампалары алыштыру | 2022 ел | 250,0 | Бюджеттан тыш чаралар | 4 300,0 кВтч | 60,0 |
| 9. | Диодлы яктырткычлар һәм лампалар, TLD лампаларын алыштыру | 2023 ел | 2,0 | җирле бюджет | 70,0 кВтч | 0,5 |
| 10 | Диодлы яктырткычлар һәм лампалар, TLD лампаларын алыштыру | 2024 ел | 2,0 | җирле бюджет | 70,0 кВтч | 0,5 » |

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының
2022 елның 30 сентябрендәге
199 номерлы карары белән
расланган

«2021-2025 елларга Татарстан Республикасы
Баулы муниципаль районында
энергияне сакчыл тоту һәм энергия
нәтиҗәлелеген арттыру»
муниципаль программасына
2 нче кушымта

2022-2025 елларга энергия ресурслары һәм су күләмнәрен куллану буенча Баулы муниципаль районының максатчан күрсәткечләре

| № п/п | Кърсщткеч атамасы | Үлчәү берәмлеге | 2020ел факт | 2021ел факт | 2022ел фараз | 2023ел фараз | 2024ел фараз | 2025ел фараз |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Күпфатирлы йортларда энергетика ресурсларын куллануның чагыштырма зурлыгы | | | | | | | | |
| 1. | Электр энергиясе | Бер кешегә Вт/ч | 616,54 | 619,60 | 619,60 | 619,60 | 619,60 | 619,60 |
| 2. | Җылылык энергиясе | Гомуми мәйданның 1 кв. метрына Гкал | 0,19 | 0,20 | 0,20 | 0,20 | 0,20 | 0,20 |
| 3. | Кайнар су | Бер кешегә куб. метр | 14,38 | 14,45 | 14,45 | 14,45 | 14,45 | 14,45 |
| 4. | Салкын су | Бер кешегә куб. метр | 37,37 | 37,55 | 37,55 | 37,55 | 37,55 | 37,55 |
| 5. | Табигый газ | Бер кешегә куб. метр | 274,12 | 272,76 | 271,41 | 270,06 | 270,06 | 270,06 |
| Муниципаль бюджет учреждениеләре тарафыннан энергетика ресурсларын куллануның чагыштырма зурлыгы | | | | | | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 6. | Электр энергиясе | Бер кешегә Вт/ч | 151,67 | 180,14 | 178,34 | 176,56 | 174,79 | 173,10 |
| 7. | Җылылык энергиясе | Гомуми мәйданның 1 кв. метрына Гкал | 0,07 | 0,08 | 0,08 | 0,08 | 0,08 | 0,08 |
| 8. | Кайнар су | Бер кешегә куб. метр | 0,15 | 0,17 | 0,17 | 0,17 | 0,17 | 0,17 |
| 9. | Салкын су | Бер кешегә куб. метр | 1,71 | 1,16 | 1,16 | 1,15 | 1,14 | 1,13 |
| 10. | Табигый газ | Бер кешегә куб. метр | 37,22 | 39,42 | 39,02 | 38,63 | 38,25 | 38,00 » |